Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

# КАРАР № XVII-3

Балык Бистәсе штп. 2021 елның 29 декабре

2022 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында торак урыннан файдаланган өчен (наем өчен түләү), күпфатирлы йортта торак урынны карап тоткан өчен түләү күләме турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156, 158 маддәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен, күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре, шулай ук гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы буенча 2022 елга түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләре өчен торак урыннан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак урынны карап тоткан өчен кушымта итеп бирелә торган Түләү күләмен расларга һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертергә,

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны транспорт, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Тажетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының 2021 елның
29 декабрендәге XVI-3
номерлы карары белән
расланды

Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен, күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре, шулай ук гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләре өчен торак урыннан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак урынны карап тоткан өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы буенча 2022 елга
Түләү күләме

| | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге | Тариф (сумнарда) | |
|---|---|---|---|
| | | 01.01.2022 дән алып 30.06.2022 гә кадәр | 01.07.2022 дән алып 31.12.2022 гә кадәр |
| Торак фонды белән идарә итү | 1 айга торак урынның гомуми мәйданының кв.м. ы | 2,28 | 2,38 |
| Торак бинаны ремонтлау | 1 айга торак урынның гомуми мәйданының кв.м. ы | 2,61 | 2,72 |
| Су үткәрү-канализация челтәрләренә агымдагы ремонт | 1 айга торак урынның гомуми мәйданының кв.м. ы | 2,61 | 2,72 |
| Үзәктән җылыту челтәрләрен агымдагы ремонтлау | 1 айга торак урынның гомуми мәйданының кв.м. ы | 1,59 | 1,66 |
| Электр белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау | 1 айга торак урынның гомуми мәйданының кв.м. ы | 1,17 | 1,22 |
| Газ белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау | 1 айга торак урынның гомуми мәйданының кв.м. ы | 0,28 | 0,29 |
| Торак урыннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) | 1 айга торак урынның гомуми мәйданының кв.м. ы | 6,16 | 6,4 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Йорт яны территориясен җыештыру | 1 айга торак урынның гомуми мәйданының кв.м. ы | 3,06 | 3,06 |